ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» 402-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Ю.З. Камалтынов, А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» 402-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 23 марты
№ 1885-VI ДС

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Ю.З. Камалтынов,
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфасына керешүе турында» 1991 елның 4 июлендәге 1141-XII номерлы Татарстан Республикасы Законын («Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы», 1992, № 2);

2) «Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфасына керешүе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 1996 елның 6 мартындагы 462 номерлы Татарстан Республикасы Законын («Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы», 1996, № 3);

3) «Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфасына керешүе турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2010 елның 15 мартындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын («Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы», 2010, № 3).

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Закон проекты белән «Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфасына керешүе турында» 1991 елның 4 июлендәге 1141-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану карала, чөнки әлеге Законда каралган хокукый җайга салу, федераль законнарга кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә, үзенең актуальлеген югалткан яисә тагын да зуррак юридик көчкә ия булган актларга, шул исәптән, Татарстан Республикасы Конституциясенә кертелгән.

Әлеге Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тануга бәйле рәвештә закон проектында шулай ук республиканың әлеге Законына үзгәрешләр кертелгән Татарстан Республикасы законнары да үз көчен югалткан дип таныла.

**«Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы закон актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы закон актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы закон проектына ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар бүлеп бирүне таләп итми.